ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 222-02-77. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№92

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

2025 елның «11» сентябре

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Региональ дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (җаваплары контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен раслый торган контроль сораулар исемлеге) рәвешен раслау турында» 2022 елның 19 маендагы 87 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең норматив хокукый актын гамәлдәге Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Региональ дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (җаваплары контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен раслый торган контроль сораулар исемлеге) рәвешен раслау турында» 2022 елның 19 маендагы 87 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2023 елның 22 сентябрендәге 112 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үтүбәндәге згәрешләрне кертергә:

атамасында «кулланылучы» сүзен «кулланыла торган» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктта «кулланылучы» сүзен «кулланыла торган» сүзенә алмаштырырга;

күрсәтелгән боерык белән расланган региональ дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (җаваплары контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәве яисә үтәмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлеге) рәвешендә:

11 пунктта:

1.2 юлның өченче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«РФ Торак кодексының 172 статьясындагы 1 өлеше; «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы (алга таба – 52-ТРЗ номерлы ТР Законы); РФ Торак кодексының 46 статьясының 1 өлеше; Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсен рәсмиләштерүгә карата таләпләрне һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы

беркетмәсенең һәм карарларының төп нөсхәләрен Россия Федерациясе субъектының дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле башкарма органына җибәрү тәртибен раслау турында» 2025 елның 30 апрелендәге 266/пр номерлы боерыгы (алга таба – 266/пр номерлы боерыгы);

1.3 юлның өченче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«266/пр номерлы боерык»;

1.10 юлның өченче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2014 елның 21 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба –209-ФЗ номерлы федераль закон); Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Торак-коммуналь хуҗалык дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2014 елның 21 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законда мәҗбүри урнаштырылуы каралган торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр тарафыннан мәгълүматның составын, срокларын һәм аны урнаштыру ешлыгын билгеләү турында» 2024 елның 7 февралендәге 79/пр номерлы боерыгы (алга таба – 79/пр номерлы боерык);

8.1 юлның өченче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«79/пр номерлы боерыкның XI бүлеге».

2. Хокук идарәсенең юридик бүлеге җитәкчесенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Аналитика һәм контроль секторына әлеге боерыкны «Интернет» челтәрендәге ТР ДТИ рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче А.В. Тыгин